**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-11-59

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СТОЛБИЩЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-11-59

2025 елның 1 сентябре — 15 номер

# БОЕРЫК

**Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында»**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 елның 14 декабрендәге 28/2 номерлы Столбище авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш эшчәнлеге, хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларын үтәү максатларында, КАРАР ИТӘМ

1. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

1.1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Столбище авылы, Совет ур., 203 адресы буенча урнашкан индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1), кадастр номеры 16:24:150121:609 булган җир кишәрлегендә шартлы рәвештә рөхсәт ителгән «Кибетләр» дән файдалануның рөхсәт ителгән “Кибетләр”төренә күчерү.

2. Билгеләргә:

2.1 Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 29 сентябрь 09 30 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге башкарма комитеты, адресы: 422624, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы, Совет ур., 103 йорт.

2.3 Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты

буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча тапшырырга: 422624, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы, Совет ур., 103 йорт.

2.4 Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2025 елның 26 сентябренә кадәр.

3. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга

.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **А.А. Абдрафеев**